Кадошкино районы Латышовка авылы терлекчелек фермасы эшендәге уныш-лары очен ин яхшы механизаторлары– Марат Каюм улы Еникаев белән Рәис Рәстәм улы Альмяшевны бvләкләделәр.

Мактау грамоталарын һәм ир-атлар очен файдалы бvләкләр - йорт очен инструментлар ООО «Магма ХД» директоры Сергей Иванович Сиушов исеменнән тапшырылды.

Марат Каюм улы Еникаев белән Рәис Рәстәм улы Альмяшев кебек механизаторлардан башка хужалыкта эш бара алмый, ди житәкчеләре һәм аларны белгәннәр.

Механизаторлар хайваннарны ашатырга, артларыннан жыярга, vлчәргә булышалар. Эш коннәр буе кайный.

- Фермада бишенче ел эшлим, ә колхозда беренче сыйныфтан комбайнчы ярдәмчесе булып эшли башладым, - дип сойли Марат Каюм улы. - Эш мина бик ошый. Жирдә хезмәт бетмәс-токәнмәс кадәр кvп. Хәзер азык, сенаж ташыйбыз, мал ашатабыз, тирес чыгарабыз. Яз, жәй коннәре, белгәнебезчә, хезмәтебезнен кайберләре vзгәрә. Ойдә дә ярдәмче хужалык белән яшибез: сарыклар, бозаулар асрыйбыз.

Маратнын напарнигы Рәис Рәстәм улы Альмяшев фермага нигез салынганнан бирле тырышып хезмәт итә. Ул:

- Авылда, тулаем алганда, эш – тавык чvпләп бетерә алмаслык кvп. Әмма туган авылны ярату хисе, Латышовка авылыбызнын якынлыгын сизеп яшәv рәхәт. Авылда яшәvнен унай яклары да, эшнен авырлыгы да бар инде. Кая жинел ул? Нәрсәгәдер яшьләребез, башка жир-ләрдәге тосле, шәһәрләргә ешрак китә. Биредә дә эш табарга була бит. Мәсәлән, фермада, - ди Рәис Рәстәм улы. - Безнен хужалыкта хезмәт хакы лаеклы, вакытында алабыз. Ә бvген житәкчеләр исеменнән грамоталар һәм бvләкләр тапшырылды. Хезмәтемнен кирәклеген, анын кадерен белv бик кvнелле.

Әйтеп китик, 392 баш малны 13 хезмәткәр тәрбияләгән хужалык-коплекс белән армый-талмый тырышып идарә итvче Зохрә Хәмзә кызы Кантеева биредә 15 ел хезмәт итә. Хезмәткәрләре хормәт итә аны; бер зур гаилә кебек эшлиләр. Мәсәлән, vгезләр vстерv цехында ике хезмәткәр – Хаким Хосәен улы Капкаев белән Рафик Кәмил улы Хансвяров бер-берсен алыштырып мал-туар vстерәләр. Бvген 53 яшен тутырган Хаким Хосәен улы хужалыкта кvптән эшли, әле «Путь Ленина» колхозы чагында ук водитель, слесарь, животновод булган. Комплекста торле эш һәм торле житәкчелек астында эшләгән. Заманалар vзгәрv белән торле эш юнәлешләре алган хужалыкта халык тырышып эшли; Латышовка авылы хезмәткәрләре хормәттә.

Н.ХӘЛИЛ